Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының
Татар Сарсазы авыл җирлеге Советы
Карары

2020 елның 20 октябре № 2/1

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Сарсазы авыл җирлеге Советының «Чистай муниципаль районы Татар Сарсазы авыл җирлегенең генераль планы турында» 2012 елның 29 ноябрендәге 11/1 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Татар Сарсазы авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Сарсазы авыл җирлеге Советының «Чистай муниципаль районы Татар Сарсазы авыл җирлегенең генераль планы турында» 2012 елның 29 ноябрендәге 11/1 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыелган урыннарда, игълан итү стендларында һәм такталарында урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль районының
Татар Сарсазы авыл җирлеге
башлыгы С.С.Мусин